Чыганак: **Бакиров, Ә. Җыр һәм музыка дәресләре: V- III класс укытучылары өчен кулланма / Ә. Бакиров .- Казан: Татар. кит. нәшр., 1967.- 136 с.**

# АЛЕКСАНДР КЛЮЧАРЕВ

Татарстанның халык артисты һәм атказанган сәнгать эшлеклесе Александр Ключарев 1906 елның 19 февралендә Казан шәһәрендә туа. 1924—1928 елларда Казан музыка техникумында, 1928—1931 елларда Мәскәү консерваториясенең композиция классында профессор Р. М. Глиэрда укый. Александр Ключарев — төрле жанрдагы музыкаль әсәрләр авторы. Аның фортепьяно, баян, кларнет һәм гобой өчен язган бик күп әсәрләре бар.

Александр Ключарев күп еллар буена татар һәм башкорт халык җырларын җыя. Ул берничә ел буена Башкортстан фәнни-тикшеренү институтының музыка бүлегенә, ТАССР сәнгать эшләре идарәсенең фольклор кабинетына җитәкчелек итә.

1941 елда Александр Ключарев «Татар халык көйләре» җыентыгының I бүлеген бастырып чыгара, 1957 елны җыентыкның II бүлеге чыга.

Александр Ключарев 1950 елда «Тау әкияте» балетын тәмамлый. Бу балет Башкортстан һәм Татарстан сәхнәләрендә еш куела. Соңгы елларда ул төрле темаларга яңа җырлар иҗат итә.

«Идел дулкыннары», «Безнең дусларыбыз» (М. Хөсәен сүзләре), «Язгы җыр» (М. Садри сүзләре), «Синең хакта» (Ә. Ерикәй сүзләре) һәм башка җырлар бүгенге көн темасына язылганнар.

Рус, татар һәм башкорт халык җырларын хор өчен эшкәртү Александр Ключарев иҗатында зур урын тота. Аның «Башкорт сюитасы» 1955 елда Мәскәүдә Башкортстан сәнгате декадасында башкарылды.

Соңгы вакытта Салих Сәйдәшевнең «Наемщик» музыкаль драмасы буенча опера язды.

Татарстан радио концертларында тыңларга мөмкин булган магнитофон язмасындагы балалар өчен җырлары: «Минем дустым — әлифба», «Ун чыпчык» (Н. Дәүли); «Безнең әби» (Г. Латыйп); «Сара мәктәпкә бара», «Уңган кыз Сара» (Б. Рәхмәт); «Хыяллар», «Рәхмәт сиңа, чыршыбыз», «Безнең дуслар», «Без синеке, интернат» (М. Хөсәен); «Укытучы кыз» (М. Ногман); «Нәҗибә», «Чылтыр-чылтыр» (Ә. Давыдов).